| ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР

2020 елның 14 августыннан                                                                 № 1

Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегенең
Тойгуҗа авылында гражданнар җыенында
үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 22 статьясы, КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 27 августында Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 сәгать 00 минутка билгеләргә. Җыен үткәрү урыны итеп Тойгуҗа авыл мәдәният йортын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Тойгуҗа авылы, Үзәк ур., 48.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2020 елда җыелган үзара салым акчаларын түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Тойгуҗа авылында су үткәргечнең техник планын төзүгә шартнамә өчен түләү,
- концессион килешү төзү буенча хезмәт күрсәтүгә шартнамә өчен түләү,
- янгын вакытында кешеләргә хәбәр итү өчен аваз сигнализациясе сатып алу,
- бензин электр генераторы, яктылык прожекторлары сатып алу,
- күрсәтмә әсбаплар урнаштыру өчен стойкалар ясау,
- спорт җиһазлары һәм инвентарьлар сатып алу».

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә - кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тойгуҗа авыл җирлеге
Башлыгы                                                                 Р.А. Сафин